ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 3, № 9; 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 3; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче өлешендәге уникенче абзацын үз көчен югалткан дип таныргa;

2) 9 статьяның беренче өлешендәге унбишенче абзацында “эчәргә яраклы су” сүзләреннән соң “һәм хуҗалык-көнкүреш сулары” сүзләрен өстәргә;

3) 16 статьяда:

а) исемендә “Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү һәм укыту” сүзләрен “Гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү” сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче өлештә “Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү һәм укыту” сүзләрен “Гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү” сүзләренә алмаштырырга;

в) икенче өлештә “Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләү һәм укыту” сүзләрен “Гадәттән тыш хәлләрдә нинди гамәлләр кылуга халыкны әзерләү” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 15-ТРЗ